| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>ЭБАЛАКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЯБАЛАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                                    КАРАР

10 нчы ноябрь 2023 ел                Ябалак авылы                № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Морза Бәрлебаш авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1, 56 маддәләре,«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге Уставының 22маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 21 ноябренә 12 сәгать 00 минутка Морза Бәрлебаш авылы, Беренче Май урамы,15А адресы буенча урнашкан мәчет бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Морза Бәрлебаш авылында **үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын** билгеләргә.

2. 2023 елның 22 ноябренә 11 сәгать 00 минутка Морза Бәрлебаш авылы,Беренче Май урамы,32Б йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең Морза Бәрлебаш авылында **үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын** билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге территориясенә кергән Морза Бәрлебаш авылыда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
- материаллар сатып алып, урам утларын ремонтлау;
- авыл җирлеге торак пункты территориясен карап тоту;
б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
- материаллар сатып алып, суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау;
- су башняларын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү, моның өчен материаллар сатып алу;
-су башнясын лицензияләү буенча түләү (су белән тәэмин итү чыганагының артскважинасын куллану өчен санитар-эпидемиологик бәяләмәне документаль рәсмиләштерү, су анализы һәм башка документлар)
в) авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:
-материаллар сатып алып янгын гидрантын ремонтлау;
г) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту».

« РИЗА» «КАРШЫ»

4. Ябалак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән әлеге карарны игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: https://ebalak-kaybici.tatarstan.ru

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы

Кайбыч муниципаль районы

Ябалак авыл җирлеге башлыгы Гыйзәтуллина М. Ф.